

6-8 августта Татарстанда узучы мәгариф хезмәткәрләренен семинар- кинәшмәсендә Россиянен 30 тобәгеннән 150 делегат катнашкан. Шул исәптән Мордовиядән мәгариф министрлыгы топ белгече Надежда Васильевна Салмова, белем бирv мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучылары - Сания Спартак кызы Саляева (Рузаевка районы Татар Пешләсе авылы), Рауза Мокаддәс кызы Юмаева (Ләмберә районы Пензятка авылы), Светлана Равиль кызы Поташова (Кадошкино районы Латышовка авылы), Альфия Фатих кызы Муртазина (Ләмберә районы Татар Тавласы авылы) семинар-кинәшмәдә булып кайттылар. Биредә педагоглар Татарстандагы милли мәгариф торышын ойрәнеп, киләчәккә эш юнәлешләре белән танышканнар. Казандагы Дуслык йортында vткән пленар утырышта Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, милли мәгариф кураторлары, татар телендә белем бирә торган мәгариф оешмалары житәкчеләре, Россия тобәкләрендә татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирvче укытучылар «Россия Федерациясе субъектларында милли мәгарифне саклау һәм vсеш булдыру» темасын яктырткан мәсьәләләрне уртага салып сойләшкәннәр. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларыбыз белем камилләштерv сертификатлары алып кайттылар.

- Тобәкләрдә милли мәгарифне яшәтv, татар телен саклап калу мәсьәләсе кинәшмәдә топ сорауларнын берсе булды. Семинар-кинәшмә кысаларында катнашучыларга Яшел Үзән районы мәгариф оешмаларынын милли мәгариф олкәсендәге тәжрибә kvрсәтелде, шулай ук kvргәзмәләр, осталык дәресләре тәкъдим ителде. Тагы бик матур чаралар Казанда vтте: «Татар авылы» этнографик комплекста булдык, Каюм Насыйри музеена сәяхәт иттек, Салават концертын карадык. Семинар-кинәшмә югары дәрәҗәдә тырышып планлаштырылган, катнашуыма бик канәгать.

Делегатлар, даими методик ярдәм kvрсәткәнгә һәм тобәкләрне уку-укыту әсбаплары белән тәэмин итеп торган очен, республика житәкчелегенә, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгына рәхмәт житкерделәр. Без дә Мордовиядән Татарстанда мордва телләрен ойрәнvче мәктәпләргә дәреслекләр һәм методик кулланмалар алып бардык, - дип фикер уртаклашты Сания Спартак кызы Саляева.

- Яшел Үзән (Зеленодольск) №1 һәм №3 гимназия-ләрендә kvрсәткән мастер-класслардан мин vземә татар телен һәм әдәбиятын укыту буенча алдынгы тәжрибә vрнәкләрен kvзәттем, бик kvп алдынгы алымнар белән эш итv юлларын алдым, - ди Рауза Мокаддәс кызы Юмаева. – Мәсәлән, татар теле һәм әдәбиятын укыту технологияләре белән бергә, милли бизәнv әйберләре булган калфак, беләзекләр ясаунын яна ысулларын ойрәндем. Кинәшмәдән баеп кайттык.

Наилә Насырова